МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ
И ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.07.2026 Казан ш. № 768-пр

«Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән алар биләгән торак урыннарны Россия Федерациясе гражданнары милкенә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 02.10.2024 № 580-пр боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
13.07.2026 № 768-пр
боерыгы белән расланган

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты (алга таба – Регламент) Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

Шартлы билгеләр һәм кыскартмалар исемлеге бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

1.2. Дәүләт хезмәте алуга гариза бирүчеләр булып «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – «РМК» ДБУ) оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны социаль найм шартларында куллану хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары тора.

Гариза бирүчеләр исеменнән тиешле тәртиптә ышанычнамә рәсмиләштерелгән законлы вәкилләре яки «Россия Федерациясе торак фондын приватизацияләү турында» 04 июль 1991 ел № 1541-1 Россия Федерациясе Законының 2 статьясы (алга таба – Закон № 1541-1) нигезендә гариза бирүче исеменнән гариза бирү вәкаләтләре булган башка затлар (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) эш йөртә ала.

Гариза бирүчеләрнең категория идентификаторы (билгеләре) бу Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә гариза бирүченең категорияләренә (билгеләренә) туры китереп күрсәтелә, аның турында белешмәләр “Дәүләти һәм

муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре билән торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торак урыннарын (алга таба – торак урыны) милек итеп тапшыру.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

«Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба - «РМК» ДБУ)

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

торакны гражданнарга милеккә тапшыру турында карар (киңәш ителгән форма әлеге Регламентка 7 нче кушымтада китерелгән), торакны гражданга милек итеп тапшыру шартнамәсе проекты белән бергә.

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (торакны гражданнарга милеккә тапшырудан баш тарту турында карар) (киңәш ителгән форма әлеге Регламентка 8 нче кушымтада китерелгән).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мәгълүмат системасында реестр язуы формалаштыру каралмаган.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерүне гариза бирүче үзе сайлаган ысул буенча ала:

гариза бирүченең шәхсән үзенә кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документның кәгазь экземпляры;

электрон документ формасында гариза бирүченең “Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләре порталы”нда (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба - Республика порталы), “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмати система” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы http://lk.eisestate.tatar.ru (алга таба - ЕИС «Имущество») шәхси кабинетына;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба - МФЦ) «РМК» ДБУдан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь формада алу өчен гариза бирүче «РМК» ДБУга мөрәҗәгать итә ала.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты, биләп торган торак урыннарын милек итеп тапшыру гаризаны (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны гариза бирүче почта аша җибәргән яки шәхсән үзе тапшырган икән, дәүләт хезмәте гариза регистрацияләнгәннән соң 34 эш көнен тәшкил итә.

2.4.2. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинет аша бирелгән булса, гаризага эш номенклатурасына туры китереп номер һәм Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетта күренеп торучы «Документларны тикшерү» статусы куелган көннән соң 34 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан МФЦ аша бирелгән булса, дәүләт хезмәте, МФЦ Регламентында каралган срокны да истә тотып, 34 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ «РМК» ДБУда гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче сайлаган ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Бердәм порталны, Республика порталын, ЕИС «Имущество»ны, «РМК» ДБУның рәсми сайтын кулланган башка түләүләр каралмаган. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты - 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросын регистрацияләү срогы

2.7.1. Гариза бирүче тарафыннан МФЦ аша бирелгән запрос МФЦдан кергән көнне «РМК» ДБУ тарафыннан регистрацияләнә.

Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦның Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелүен раслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән регистрация номерлы расписка бирелә.

2.7.2. Гариза Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша эш көннәрендә юлланса, «РМК» ДБУ тарафыннан кергән көнендә регистрацияләнә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

Гариза Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гариза җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү ала.

2.7.3. Гариза почта аша юлланса, «РМК» ДБУ тарафыннан кергән көнендә регистрацияләнә.

Гариза почта аша юлланса, гариза бирүчегә гариза «РМК» ДБУга кергән көнне электрон почта белән гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү юллана.

2.7.4. Гариза бирүче «РМК» ДБУга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул ук көнне регистрацияләнә.

Гариза бирелгән көнне «РМК» ДБУ хезмәткәре гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән расписка бирә.

2.8. Требования к помещениям, в которых предоставляется государственная услуга

Требования к помещениям, в которых предоставляется государственная услуга, размещаются на официальном сайте ГБУ «РИК», Едином портале, Республиканском портале, ЕИС «Имущество».

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр «РМК» ДБУның рәсми сайтына, Бердәм порталга, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша «РМК» ДБУга мөрәҗәгать итсә, гариза бирүчегә консультация бирелә ала.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, гариза бирү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү өлешендә, теләсә кайсы МФЦда, үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда, мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына карамастан сайлавы буенча экстерриториаль принцип буенча гамәлгә ашырыла.

2.10.4. МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге, шул исәптән МФЦның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча МФЦга җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү мөмкинлеге каралган.

2.10.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның мәгълүмат системаларыннан кәгазьдә документлар бирү, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне таныклау мөмкинлеге каралмаган.

2.10.6. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Берләм порталда, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ) туры китереп алдарак расланган документлар һәм мәгълүматны Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән запросның үтәлеше турында белешмә алу;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш)

тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять итү.

Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да электрон формада запрос тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гариза бирү зарурлыгы юк.

2.10.7. Гариза формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзаллаган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан запросның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән запросларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган гаризаларга да.

2.10.8. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», «РМК» ДБУ телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче «РМК» ДБУның, күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегә раслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итәргә каршылык тудырмый.

2.10.9 Кәгазь чыганактагы документ яисә кәгазь чыганактагы электрон документ нөсхәсе рәвешендә рәсмиләштерелгән балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле алырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ турындагы белешмәләрне, фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта) күрсәтә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе күрсәтелгән затка шәхсән аның шәхесен таныклаучы документ күрсәтелгәндә бирелә.

Балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәтен күрсәтүнең кәгазьдәге документ яисә кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәсе, әгәр гаризада мөрәҗәгать итүче балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәсен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелми.

2.10.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомствоара электрон арадашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге

2.11.1. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән: алар мөрәҗәгать итүче үзе мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка, һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документларга бүленә.

2.11.2. Гариза формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.11.3. Торак урынны хосусыйлаштыруда катнашудан баш тартканда, аны хосусыйлаштыруда катнашу хокукына ия гражданнар әлеге Регламентның 6 нчы

кушымтасында күрсәтелгән форма буенча тиешле гариза йә торак урынны хосусыйлаштыруда катнашудан нотариаль рәсмиләштерелгән баш тарту бирәләр.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен, һәм аларны гариза бирүчегә кайтару өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) шушы регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр категориясенә керми торган зат мөрәҗәгате;

2) документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән;

3) әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау.

4) гариза бирүче тапшырган документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар;

5) гариза формасында юлларның дөрес тутырылмавы, шул исәптән, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы интерактив формадагы гаризаны (ышанычсыз, тулы булмаган яки дөрес булмаган тутырылыш).

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.12.3. Түбәндәге шартларның берсенең генә булса да булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

- гариза бирүче тапшырган документларда дөрес түгел белешмәләрнең булуы;

- торакның түбәндәге очракларында:

тузган торак халәтендә;

тулай торак;

ябык хәрби шәһәрчектәге йортта;

- хезмәт вазыйфасы белән бәйле торак, искәрмә булып совхозларның һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләрнең, аларга тигезләштерелгән торак фонды һәм халыкны социаль яклау стационар учреждениеләренең авыл җирлегендә урнашкан торак фонды тора;

- гариза бирүче элегрәк торакны приватизацияләүдә катнашкан булган, № 1541-1 Законның 11 статьясында күрсәтелгән очрак искәрмә булып тора;

- - торак оператив идарә хокукында «РМК» ДБУга беркетелмәгән;

- - торак кадастр исәбенә куелмаган;
- - торак бүлмәнең яшәргә яраксызлыгын тану турында вәкаләтле җирле үзидарә ораганының карары булу.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү шулай ук мөрәҗәгать итүченең үз гаризасын һәм документларын язмача чакыртып алуы йә торак урынны гражданнар милкенә тапшыру шартнамәсенә кул куелганчы торак урыннан социаль наем шартларында файдалану хокукына ия гаилә әгъзаларының берсенең әлеге шартнамәне төзү (хосусыйлаштыруда катнашу) ниятләренең булмавы турында язмача мөрәҗәгате һәм/яки мөрәҗәгать итүченең торак урынны хосусыйлаштыруга ризалыгын язмача чакыртып алуы нигезендә туктатыла.

Бу очракта, калган мөрәҗәгать итүчеләргә гаризаны язмача кире алу теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән язмача баш тарту җибәрелә.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, «РМК» ДБУ мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), административ процедура таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны гамәлгә ашыру, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гамәлгә ашырыла торган чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны), мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә

кабатланырга рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын күздә тоткан бүленеш каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене профильләү;

2) гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати арадашлык;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан эшләү (проактив) режимында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның запросы статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат аша;

- Бердәм портал аша;

– Республика порталы аша;

– ЕИС «Имущество» аша;

– башка сервислар һәм ысуллар кулланып (булса).

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (https:// www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы – ЕИС «Имущество» (http://lk.eisestate.tatar.ru);
4. «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесе – («РМК» ДБУ);
5. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – МФЦ.
6. Россия Федерациясе Гражданлык кодексы –РФ ГК;
7. «Россия Федерациясендә торак фондын приватизацияләү турында» 1991 елның 4 июлендәге № 1541-1 Россия Федерациясе Законы

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | торак урынын гражданнарга милеккә тапшыру турында карар, торакны гражданга милек итеп тапшыру шартнамәсе проекты белән бергә | «РМК» ДБУга оператив идарә хокукында беркетелгән торак урыннарын социаль найм шартларында файдалану хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары | 1А |
| 2. | | Гариза бирүченең вәкиле | 2А |

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
3 нче кушымта

Исчерпывающий перечень документов, необходимых для предоставления государственной услуги

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группа документлары саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүче үзе тапшырырга тиешле документлар | | | |
| 1. | 1А-2А | кәгазь документ формасындагы гариза | почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| | 1А-2А | электрон формадагы гариза | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» (гризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла) |
| 2. | 1А-2А | Шәхесне раслаучы документ | МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 1А-2А | Шәхесне раслаучы документ күчермәсе | почта аша юллаганда, МФЦга яки |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә, Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» |
| 4. | 2А | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 5. | 1А-2А | 14 яше тулган һәм өлкәнрәк гаилә әгъзаларының паспорт күчермәсе (2, 3, 5 – 12, 14 – 19 битләренең күчермәләрен алу зарури) (шәхесне раслаучы башка документ) | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 6. | 1А-2А | Гаиләнең 14 яше тулмаган балигъ булмаган әгъзаларының туу турында таныклыклары, аларның туу турындагы таныклыклары башка чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән икән, таныклыкның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсе. | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 7. | 1А-2А | гражданнарның социаль найм шартларында торактан файдалану | Бердәм портал, Республика |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хокукын раслаучы документ | порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 8. | 1А-2А | торакның техник планы (техник паспорт) күчермәсе | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 9. | 1А-2А | гражданның элегрәк, 1991 елның 4 июленнән соң, даими яшәгән урыннарыннан (андый мәгълүмат паспортта булмаса) белешмә (ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балалар арасыннан “Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балаларны торак белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законынаның 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 12 январендәге № 8-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы тәэсире булган затлар чыгарылма булып тора). | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 10. | 1А-2А | Элек яшәгән урыннарда түләүсез приватизация хокукын файдаланмау | Бердәм портал, Республика |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | турында 2000 елның 1 январена кадәр Россия Федерациясе территориясендә күчемсез милеккә хокукларны теркәү эшен башкарган вәкаләтле органнан Россия Федерациясе субъекты территориясендәге законнар таләпләренә туры китереп бирелгән белешмә (ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балалар арасыннан “Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балаларны торак белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законынаның 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 12 январендәге № 8-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы тәэсире булган затлар чыгарылма булып тора). | порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 11. | 1А-2А | Ата-ананың (уллыкка алучыларның), попечительләрнең torakны приватизацияләргә рөхсәт кәгазе, торакта бары тик 14-18 яшьлек балигъ булмаган балалар, яисә үзен-үзе карау сәләте чикле гражданнар яшәсә | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 12. | 1А-2А | торак урынны хосусыйлаштыруда катнашудан баш тарту турында гариза, йә торак урынны хосусыйлаштыруда катнашудан нотариаль рәсмиләштерелгән баш | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тарту - аны хосусыйлаштыруда катнашу хокукына ия булучылар арасыннан торак урынны хосусыйлаштыруга ризалык биргән, әмма хосусыйлаштыруда шәхсән катнашудан баш тартуны белдергән гражданнар булганда | юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, дәүләт хезмәте күрсәтелү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра алган документлар | | | |
| 1. | 1А-2А | күчемсез милек объекты һәм аның хокук ияләре турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан белешмә (алга таба - ЕГРН), Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр); | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 2. | 1А-2А | аерым затның үзендә булган күчемсез милеккә хокук (хокуклар) турында ЕГРН өземтәсе ТР буенча Росреестрдан | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 1А-2А | торакны биләүченең гаиләсендәге 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларның тууы дәүләти регистрацияләнүе турында белешмә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гражданлык хәле актларын теркәү идарәсеннән (балигъ булмаган бала 2018 елның 1 октябренә кадәр туса) яки Татарстан | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсеннән (балигъ булмаган була 2018 елның 1 октябреннән соң туса) | иткәндә |
| 4. | 1А-2А | опекун, попечитель билгеләнүе турында карар, опекунлык таныклыгы күчермәсе, опекунлык һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләү өчен беренчел рөхсәт - бары тик 14 яше тулмаган балалар яшәгән торак приватизацияләнгәндә, эшчәнлеккә сәләтсез гражданнар - җирле үзидарәнең вәкаләтле органыннан | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 5. | 1А-2А | опекунлык һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләү өчен рөхсәте, опекунлык таныклыгы күчермәсе - бары тик 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган балалар яки эшчәнлеккә сәләте чикле гражданнар яшәгән торак приватизацияләнгәндә – җирле үзидарәнең вәкаләтле органыннан | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 6. | 1А-2А | торак урынны мөрәҗәгать итүчеләрдән аерым яшәүче, әмма торак урыннан файдалану хокукын югалтмаган балигъ булмаган балалар катнашыннан башка җирле үзидарәнең вәкаләтле органыннан милеккә тапшыру турында опека һәм попечительлек органнарының рөхсәте | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 7. | 1А-2А | хосусыйлаштырыла торган торак йортта гариза бирүчеләр белән бер адреста яшәгән яки торган урын буенча теркәлгән, шулай ук, миграцион исәптә булган затлар | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | турында белешмә, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан | юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |
| 8. | 1А-2А | торак йортны яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар, җирле үзидарәнең вәкаләтле органыннан | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки «РМК» ДБУга мөрәҗәгать иткәндә |

Искәрмәләр:

1. Торак урынны гражданнар милкенә тапшыру турындагы гаризага теркәлә торган документ күчермәләре нотариуста раслана ала. Нотариус раслаган күчермәләр булмаган очракта, түбәндәгеләр кабул ителә:

дөреслеге җитәкче яисә вазыйфаи затның вәкаләтләре булган зат имзасы һәм оешма мөһере (булса) белән расланган документлар күчермәләре;

документның төп нөсхәсе күрсәтелү шарты белән, расланмаган документлар. Бу очракта документны кабул итүче документның күчермәсен аның төп нөсхәсе белән чагыштыра.

2. Ышанычнамә буенча гаризаны рәсмиләштергәндә вәкаләтле зат паспорт (шәхесне таныклаучы башка документ), нотариаль таныкланган ышанычнамә йә законнар нигезендә нотариаль таныкланган ышанычнамәгә тиңләштерелгән ышанычнамә тапшыра.

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группадагы документлар саны |
|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр (аларны кире кайтару) | | |
| 1. | 1А-2А | әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләр категориясенә кермәгән затның мөрәҗәгате; |
| 2. | 1А-2А | документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән |
| 3. | 1А-2А | әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау |
| 4. | 1А-2А | гариза бирүче тапшырган гаризада һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар |
| 5. | 1А-2А | гариза формасында юлларның тулысынча тутырылмавы, шул исәптән, Бердәм порталда, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы интерактив формадагы гаризаны (чын булмаган, тулы булмаган яки дөрес түгел) |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | | |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А-2А | гариза бирүче тапшырган) документлардагы мәгълүмат дөреслеккә туры килми |
| 2. | 1А-2А | торакның түбәндәге очракларында:<br>тузган торак халәтендә;<br>тулай торак;<br>ябык хәрби шәһәрчектәге йортта; |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | 1А-2А | хезмәт вазыйфасы белән бәйле торак, искәрмә булып совхозларның һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләрнең, аларга тигезләштерелгән торак фонды һәм халыкны социаль яклау стационар учреждениеләренең авыл җирлегендә урнашкан торак фонды тора |
| 4. | 1А-2А | гариза бирүче элегрәк торакны приватизацияләүдә катнашкан булган, № 1541-1 Законның 11 статьясында күрсәтелгән очрак искәрмә булып тора |
| 5. | 1А-2А | торак оператив идарә хокукында «РМК» ДБУга беркетелмәгән |
| 6. | 1А-2А | торак кадастр исәбенә куелмаган |
| 7. | 1А-2А | торак бүлмәнең яшәргә яраксызлыгын тану турында вәкаләтле җирле үзидарә ораганының карары булу |
| 8. | 1А-2А | мөрәҗәгать итүче үзенең гаризасын һәм документларын язмача чакыртып алу йә торак урынны гражданнар милкенә тапшыру шартнамәсенә имза салынганчы социаль наем шартларында торак урыннан файдалану хокукына ия гаилә әгъзаларының берсенең күрсәтелгән шартнамәне төзү (хосусыйлаштыруда катнашу) ниятләренең булмавы турында язмача мөрәҗәгате һәм/яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан торак урынны гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан хосусыйлаштыруга үз ризалыгын язмача чакыртып алу |

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
5 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

«Республика мөлкәт казнасы» ДБУ директорына

__________________________ адресы буенча яшәүче

торакны биләүче гр.________________________,

_______________________________________

тел.________________________________________;

эл.адрес:__________________________________

Гариза

«Россия Федерациясендә торак фондын приватизацияләү турында» 1991 елның 4 июлендәге № 1541-1 Россия Федерациясе Законы нигезендә
Республика Татарстан, ______________ шәһәре, ____________________ урамы, ________ номерлы йорт, корпус № _______, фатир (бүлмә) _____________ адресы белән урнашкан
без (мин) социаль найм шартнамәсе нигезендә биләп торган торакны __________ бүлмәле фатирны (бүлмә(ләр)не ________________________________________________ милек итеп бирүегезне сорыйм

Торакны милеккә бирү шартнамәсе һәм приватизацияләнгән фатирны, торак 1ортны һәм йорт алды территориясен каарп тоту шартнамәсен имзалау вәкаләтләре: ________________________________________________________________________

________________________________________________________________

*(Ф.И.ӘИ* (соңгысы булса) *гаилә әгъзасы – булачак милек иясе, бер затның милке булганда яис әуртак милек булганда гаилә әгъзаларының берсенең Ф.И.ӘИ* (соңгысы булса)*)*

________________________________ ________________________________

*(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)* *(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)*

________________________________ ________________________________

*(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)* *(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)*

________________________________ ________________________________

*(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)* *(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)*

________________________________ ________________________________

*(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)* *(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *һәм уртак милек булса гаилә әгъзасының имзасы)*

2. Торакны милек итеп привазизацияләү

*(Ф.И .ӘИ.* (соңгысы булса). *торакны приватизацияләүче гаилә әгъзасы)*

1.________________________________ 3.________________________________

2.________________________________ 4.________________________________

ризалык бирә: *(аскарак Ф.И.Ә.* (соңгысы булса) *куела һәм 14 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк приватизациядә катнашмаучы гаилә әгъзалары имзасы).*

1.________________________________ 4.________________________________

2.________________________________ 5.________________________________

3.________________________________ 6.________________________________

3. Әлеге таблицада барлык гаилә әгъзалары турында мәгълүмат регистрация исәбе буенча күрсәтелә һәм 14 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәкләрнең имзалары куела:

| Фамилия, имя, этисе исеме (соңгысы булса) (ышанычлы вәкилне кертеп) | Туган датасы (көн, ай, ел) | Яшәгән урыны регистрациясе адресы | Паспорт (серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән) | Регистрация датасы һәм төре | Өлеш ɔлыгы | 14 яшьлек һәм өлкәнрәк гаилә әгъзаларының имзасы | Алдарак приватизациядән катнашуы турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

*Искәрмә. 6 нчы графа торак гомуми өлешле милеккә алынганда тутырыла.*

______________________________________________________________________/________________/__________/
***(гариза бирүченең Ф.И.ӘИ.** (әтисе исеме – булса) тулысынча**)*** ***(имза)***

***(дата)***

Гариза бирүче белән арадашлык нинди ысул белән гамәлгә ашырыла ____________________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә ___________________________________________________;

(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземпляры рәвешендә кәгазьдә; Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетка, ЕИС «Имущество»га);

- «РМК» ДБУга бирергә __________________

_______________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземплярлары рәвешендә кәгазьдә)

Балигъ булмаган балага карата дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен турыдан-туры «РМК» ДБУда бирүегезне сорыйм

_____________________________________________________________________________________________

(күрсәтелә: кәгазь саклагычтагы документ рәвешендә яисә кәгазь саклагычтагы электрон документның нөсхәсе рәвешендә)

шәхсән үземә ______________________________________________________________________________________

балигъ булмаганның гариза бирүче булмаган башка законлы вәкиленә ____________________________________________

_____________________________________________________________________________________________

(фамилия, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булса), шәхесне раслаган документ турында белешмә)

_____________________________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________ __________ «___» _______ 20_ ел

(гариза бирүченең яки гариза бирүченең вәкиленең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булса) (имза) (дата)

Гариза кабул ителде *"____"________________20___ел* һәм гаризаларны исәпкә алу һәм торакны приватизацияләү буенча документлар бирү кенәгәсендә теркәлде. *№* _________.

Гариза бирүчеләрнең мәгълүматлары тикшерелгән,шәхесне раслаучы документта күрсәтелгән һәм «Республика мөлкәт казнасы» ДБУда булган мәгълүмат белән тәңгәл килә.

Гаризаны кабул итеп алган хезмәткәр ________________________/________/
*(имза)* *(Ф.И.ӘИ.)*

Килештерү өчен бирелгән:
Учреждение директоры ______________________/_________________/
(имза) (Ф.И.ӘИ.)

*М. П.*

/гаризаның икенче ягы/

Биләгән торак урынны хосусыйлаштыруга ризалыкны һәм шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыкны раслый торган гаилә әгъзалары составы һәм имзалары:

| № п/п | Ф. И. ӘИ. (тулысынча) (атасының исеме булган очракта) РФ Кораллы Көчләрендә хезмәт итүче, командировкада, иректән мәхрүм итү урыннарында булган һ.б. затларны исәпкә алып | Туган көне (көне, ае, елы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт белешмәләре, туу турында таныклык (серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән, бүлекчә коды) индивидуаль лицевого шәхси счетның страхка номеры (СНИЛС) | Регистрация датасы | Өлеш күләме | 14 яшь һәм өлкәнрәк булган гаилә әгъзалары имзалары+ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | | | Биләүче | | | | |
| 2 | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | |

Искәрмә:
1. 8 нче графа торак урыны уртак өлешләрдә милеккә алынганда тутырыла .
2. 14 яшькә кадәрге балигъ булмаган балалар өчен ата-аналатрның берсе, опекун имза куя.
3.14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган балалар ата-аналарның берсе, попечитель ризалыгы белән имза куя. Ата-аналарның, опекунның, попечительнең ризалыгы имза белән раслана.

Гариза кабул ителде «______» __________ 20___ ел һәм торак урыннарын хосусыйлаштыру буенча гаризалар кабул итү һәм документлар тапшыруны исәпкә алып бура кенәгәсендә № _______ номеры белән теркәлде

Гариза бирүчеләрнең белешмәләре тикшерелгән һәм аларның шәхесен раслаучы документларга туры килә ___________________________________________________________________________________________________________________________________________________

(хезмәткәрнең фамилиясе, инициаллары) (имза

Гаризага
кушымта

Гаризага теркәлгән документларның исемлеге

| Документның атамасы | Битләр саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)

_______________________________________ _______________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

«РМК» ДБУ белгече

_______________________________________ _______________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)
Барлык документлар 1 данәдә тапшырыла.

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
6 нчы кушымта

Киңәш ителгән форма

«Республика мөлкәт казнасы» ДБУ
директорына
______________________________________________
(фамилия, инициаллар)

от ___________________________________________
(фамилия, инициаллар)

ГАРИЗА

Мин, ______________________________________________________________,
паспорт __________________________бирелгән______________________
(серия, номер)

___________________________________________________________________
Бирелү датасы __________________, бүлекчә коды _________________,
адресы буенча яшәүче:_____________________________________
___________________________________________________________________

«Россия Федерациясе торак фондын приватизацияләү турында» 04 июль 1991 ел № 1541-1 Россия Федерациясе Законына таянып, Татарстан Республикасы, шәһәр ____________, урам ______________________, йорт № ________, корпус № (литер) ______, фатир (бүлмә) № ________ адресы буенча урнашкан торак урынын хосусыйлаштырырга ризалык бирәм.

Үзем хосусыйлаштыруда катнашмыйм. Мине торак урыннарның гомуми милкендә катнашучылар исемлегенә кертмәвегезне сорыйм. Хосусыйлыштыруда катнашудан баш тартуның нәтиҗәләре белән таныштым.

Бу ризалык гариза язган көннән башлап, ризалыкны язмача сорап алган көнгә кадәр гамәлдә.

Гариза бирүченең имзасы

_______________________________________________ ________________
(гариза бирүченең, вәкиленең фамилиясе, исеме, этисенең исеме (булса)) (имза)

Дата_______________________

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре билəп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
7 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

«Республика мөлкәт казнасы»
дәүләт бюджет учреждениесе

Торакны граждан милкенә бирү турында карар

Ф.И.ӘИ. (этисенең исеме - булса)
(гариза бирүченең атамасы):
_______________________________

Регистрация адресы:
_______________________________
_______________________________

«Россия Федерациясе торак фондын приватизацияләү турында» 04 июль 1991 ел № 1541-1 Россия Федерациясе Законына таянып Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карары нигезендә

(______________________________________________)
(оператив идарәгә беркетелгән)
(______________________________________________________),
(торакны махсус торак фонды составыннан чыгару)

гариза гр______________________________________________ биләгән,
Татарстан Республикасы дәүләт торак фондына караган __________________ фатирны милек итеп бирергә – ____________________________________ адресы буенча урнашкан, кадастр номеры ___________, мәйданы ______ кв.м.

Торакны милеккә бирү турында шартнамә төзү максатыннан алдан язылу өчен Сезгә _________________________телефон аша “РМК” ДБУга мөрәҗәгать итү кирәк.

______________________ № ________

________________________________________________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.ӘИ. (этисенең исеме - булча)

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнң административ регламентына
8 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарның тәкъдим ителә торган формасы

______________________________
(физик затның фамилиясе, инициаллары)

______________________________
регистрация адресы

____________________________ № ________белән теркәлгән гариза буенча түбәндәге нигезләрдән чыгып дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:___________________.

Баш тарту сәбәпләренә ачыклык кертү: :_________________________________.

_____________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүчегә баш тарту сәбәпләре турында хәбәр ителә, аларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы баш тартуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән, аларга туры килмәве дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп)

Өстәмә хәбәр бирәбез: _______________________________________.
(хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук булган очракта башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә)

Сез күрсәтелгән кимчелекләрне төзәткәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән кабат “РМК” ГБУга мөрәҗәгать итә аласыз.

Әлеге баш тартуны судка кадәр “РМК” ДБУга шикаять итәргә мөмкин, судлашу тәртибендә дә шикаять итәргә була.

Вазыйфа ______________________ (Фамилия, инициаллар)
(имза)

Башкаручы (Фамилия, инициаллар)

______________________________

(юашкаручының контактлары)